Укытучы эшен игенче белән чагыштырырга яратам, чонки игенче кечкенә генә орлыкларны туфракка чәчә, армый-талмый жирне ашлый, эшкәртә. Шулай зур авырлык белән иген vстерә. Ул vстергән игеннәр ботен халыкнын табын тvрендә. Укытучы да нәни баланын кvнеленә белем орлыклары сала, белем бирә, тәрбияли. Ә шул балалар, vсеп житкәч, алган белем һәм тәрбиясен кулланып, туган илгә хезмәт итә. Шундыйларнын берсе Кадошкино районы Большие Поляны башта урта, хәзер топ гомуми белем бирv мәктәбендә филолог булып хезмәт иткән Нурия Абдулла кызы Ахметова. Гап-гади бер авыл укытучысы. Авылда туып-vскән, vзе белем алган һәм туган мәктәбендә гомере буе балаларга белем биргән ул. Башта башлангыч сыйныф укучыларына, аннары рус, бар иде вакыт, ана теле һәм әдәбияты укытучысы булып та хезмәт итте. Нурия ханым зыялы, хезмәт соючән, кешелекле, игелекле, Исалыларга хас кунакчыл, ачык йозле, тыйнак кvнелле, рухи зәвыклы, әхлакый шәхес, яшь гражданин тәрбияләргә тырышты. Бу сыйфатларны улы Динар педагогик тәржибәсенә дә нигез буларак тапшырды. Татарларга хас сыйфатларны - олыларны ихтиран итv һәм кечеләрне ярату орлыгы улында булдырды. Динар улы педагогы һәм наставнигы булганы очен, тормыш тәжрибәсенә нигезләнгән мәнгелек кешелеклелек кыйммәтләрен булдырган очен әнисе Нурия Абдулла кызына рәхмәтле. Хормәте, тәжрибәсе булмаган кичәге студентны әнисе vзен укыткан укытучылар һәм укучылар коллективына керергә, нәрсәгәдер ирешергә ярдәм итә. Сайлаган профессиянне аклар очен остенә карап торган кvзләргә тугры булырга кирәк, ди. Вузда язылган китапларда бик жинел һәм бик гади иттереп бирелә, ә тормышта һәрбер бала – шәхес. Ана белем дә бирә белергә, дус та була белv кыйммәтле. Нәкъ Нурия Абдулла кызы педагог булу нечкәлекләренә ойрәтә дә улын. Динарга әнисе педагог булуда гына тvгел, тормышта да наставнигы. Белгәнебезчә, укытучы ул мәктәптә дә, ойдә дә vрнәк. Кондез- жәмгыять белеме һәм тарих буенча дәресләр, тоштән сон - секция эше, тvгәрәкләр, гадәттәгечә ял коннәрендә - торле чаралар. Ахметовта - ярышлар. Динар Наиль улына (остәмәгә) физкультура дәресләре дә бирәләр. Вакытлыча, әмма кире какмый житәкче соравын - ала. Ана бу эш яналык булмый. Исалыларнын элекке мактаулы исемен югары кvтәрvче булырга тиеш бит. Адымнан-адымга уныш жимешләре олгерә. Большеполянка спортсменнар

командасы - районда, аннары республика ярышларында катнашучылар һәм призерлар-жинvчеләр була башлыйлар. Алар: Мухортова Елена, Ахметова Самира, Кильдеев Роберт, Долотказина Диляра, Башмакова һәм башкалар. Бу спор

т казанышлары турында иде.

Без XXI гасырда яшибез. Хәзер укучыларнын акыл vсешен булдырунын әһәмияте, зарурлыгы тагын да артты. Демократик жәмгыять, донья һәм анда vзеннен урынынны vзенчә kvзаллау хокукы һәр шәхеснен фикерләv сәләтенә ия булуны таләп итә. Мондый сәләт кече яшьтән формалаша башлый, һәм уку-укыту, тәрбия системасы белән бәйле. Биредә жәмгыять, тарих белеме зур урын алып тора. Предметлар укытучысы буларак та унышларга ирешә яшь педагог Ахметов. Анын укучылары район, республика олимпиадаларында һәм конкурсларда катнашалар, урыннар яулыйлар. Мәсәлән, Ахметова Самира һәм Ахметова Альмира, Кильдеев Роберт, Долотказин Альберт һәм Долотказин Марсель һәм башкалар. Үзе дә укытучы буларак торле чараларда актив. Профессиональ осталык конкурсында «Педагог профессиясенә тугрылык» номинациясендә жинеп чыга Динар Наил улы Ахметов.

Бер яктан унган – торле яктан унган, диләр. Динар Наиль улы тормыш иптәше Светлана Камиль кызы (мәктәп ашханәсендә эшли) белән тату гаилә тозиләр. Кызлары - 10 сыйныф укучысы Альмира белән 6нчы укучысы Самира бvген уку алдынгылары. Ахметовлар авыл һәм район гаилә ярышларында катнашалар, призлы урыннар яулыйлар. Барысын да булдыралар. Әтисе Наиль Касим улы һәм әнисе Нурия Абдулла кызы барлык яктан улларына терәк булмасалар, ярдәм итмәсәләр, Динарлары шулкадәр унышлы булмас иде дип уйлыйм. Педагог буларак та, гаиләдә дә зур унышларга ирешә алмас иде. Яраткан эше булган кеше бәхетле, дибез. Кеше хезмәтенә тугры икән, ул сәләтле. Ә укытучы булырга һәм педагогик хезмәтендә унышларга сәләтле кешеләр генә ирешә. Мона дәлил Динар Ахметовнын торле грамоталары, Гособрание Рәхмәте.

- Яраткан эшен булу – бәхет. Торле дәрес алымнары кулланып, укучыларда фәнгә кызыксыну уятып ныклы белем бирсәм, аларда әдәплелек, кешелеклелек сыйфатлары тәрбияли алсам, мин илем алдында бурычымны vтим һәм vземне Россиянен тулы хокуклы гражданины итеп саныйм, ди әнгәмәдәшем сvзен йомгаклап.

Наилә Насырова